Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

№ 2 03 ноябрь 2022 ел

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Азат авылында үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 14 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге Азат авылында үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Азат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме; I төркем инвалидлардан, БВС ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне) , мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итүдән тыш; җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга алынган акчаларны юнәлдерергә ризамы:

**1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

**- - Азат торак пункты чикләрендә юл полотносын урнаштыру шул исәптән: грунтны күтәрү, вак таш сатып алу, вак таш салу, тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);**

**--торак пункт эчендәге юлларны кышкы карап тоту, шул исәптән кардан чистарту, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу;**

**2. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:**

**- суүткәргеч челтәрен ремонтлау (материаллар сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), Азат авылында су башнясы өчен автоматика сатып алу.**

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Аксубай районы Азат авылының Үзәк 1А урамы адресы буенча урнашкан кибет янында халык җыены үткәрергә.

4.Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыелган урыннарда, стендларда һәм белдерү такталарында асып кую юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-

коммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар анның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы А.В.Макаров